Татарстан Республикасы фән һәм мәгариф министрлыгы
Лаеш муниципаль районы Муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе
Олы Кабан урта гомумбелем мәктәбе

# “Минем педагогик осталыгым”

## темасына

## эссе

эшләде: НигъмәтҗәноваГ.Ф.,
югары квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Олы Кабан, 2018.

Кайларга илтсә дә юлларым,
Мәктәпкә тоташа уйларым...
Өзелә күрмәгез, юлларым!
Туктала күрмәгез, уйларым!

С. Әхмәтҗанова

Иртә. Һәр тараф тын. Кызарып кояш чыга. Көн туа. Бар кеше дә эшкә ашыга. Кемдер машинада элдертә, шаулап торган калага китә. Мин дә таныш сукмак буйлап көн саен эшемә ашыгам. Таныш сукмак... Әлбәттә, бер үк юлдан йөреп, такыр сукмак салынган. Һәркемнең үз тормышы, үз сукмагы, үз юлы... Үз сукмагым мине мәктәпкә илтә. Нәни сукмаклар бик күпләрне мәктәпкә алып килә. Сабый балаларын җитәкләгән ата-аналар бигрәк кызу бара. Ә үз сукмакларыннан йөрергә шомарып беткән кызлар һәм малайлар әллә ни ашыкмый кебек. Көлгән, шаярган булалар. Ә менә тиздән олы юлга әзерләнүче егетләр һәм кызлар борчулы күренә, мөгаен, киләчәк турында уйланалардыр. Киләчәктә аларны нәрсә көтә?! Һәркем үз дөньясына чумган...

Уйлар, уйлар... Алар җитез, алар алдан йөгерә. Уйлар мине мәктәп сукмагыннан читкә, кирегә сөйри. Җитәр, Гөлсинә, күп тырыштың, инде җитәр. Яраткан әни, дәү әни булып өйдә утырыр вакытың җитте бит. Мәктәп сукмагын күпме таптарга була инде? Шушы юлда югалткан саулыгың, көч-куәтең кызганыч түгелме?!

Соңгы елларда педагогик философиядә “корбанчылык” теориясе турында еш сөйли башладылар. Ләкин безгә, рус мәктәбендә татар теле укытучысы булып эшләүче татар хатыннарына, бу “ тапталган”, ягъни “иске” тема инде. Гаиләбездән, балаларыбыздан “йолкып” алынган вакыт һәм үзебезнең саулык, йөрәк каныбыз хисабына яуланган үрләр... Мең ата-ана баласын үзеңнеке итеп карап, күңел җылыбызны тамчылап бүлеп биргәндә, өйдәгеләргә бик игътибар калмый шул... Аларның әрнү-үпкәләрен еллар үткәч, саргайган кәгазь битләреннән генә күрәсең. Иске кәгазьләрне актарганда, улымның “Минем укытучым” дигән иншасы кулга килеп керде.

“... Укытучы сүзе белән мин, 3-4 яшьләр тирәсендә, әнием эшкә чыккач “таныштым”. Моңарчы гел миңа әкиятләр укыган, минем белән рәсемнәр ясаган, шигырьләр өйрәткән әнием, шул көннән соң үзгәрде дә куйды. Иртән иртүк чыгып китә, кич кайта, өстәл янында нидер актара, яза. Янына килсәм: “Комачаулап йөрмә әле, улым, эшем күп, әнә уенчыкларың белән уйна,”- ди. Менә шулай итеп мин үзем дә сизмичә, “укытучы малае булганмын”.

Белсәгез иде, сез укытучы малае булуның авырлыкларын?! Ә укытучы булуы тагын да авыррак бит".

Бу юллар мине сискәндереп җибәрде. Уйланырга мәҗбүр итте. Инде ничә еллар балалар укытып, үземнең иң авыр хезмәт башкаручы һөнәр ияләренең берсе булуым турында уйлап та караганым юк иде. Мәктәптә эшли башлавымның беренче көненнән үк мин үземне иң бәхетле кеше итеп тойдым. Мәктәпкә сөенеп барам. Мәктәп бусагасыннан атлап керүгә, күңелемне рухи ләззәт биләп ала. Мине яраткан укучыларым көтә. Мин алар өчен шатланам да, борчылам да. Менә шулай утыз елга якын гомер үтеп тә киткән.

Без катлаулы чорда яшибез. Яшәеш бүген имтихан тота: кешелек дөньясы экологик, экономик, этник проблемаларның чолганышында калды. Тормыш безне тагын бер сынап карый сыман...

Үз һөнәреңне ничек кенә яратсаң да, рус авылында телебезне өйрәтү бер дә җиңел бирелми. Мин гомерем буе яңалыкка, камиллеккә омтылып яшәдем. Яңалык эзләп, коммуникатив технология нигезләрен өйрәндем. Р.Хәйдәрова методикасын кулланып, рус телле укучыларны сөйләшергә өйрәтәм. Моның өчен аларда аралашу ихтыяҗы тудырам.

Фәнемә кызыксыну уяту өчен проектлар төзеп, презентацияләр әзерләп, җанлы да, заманча да дәресләр үткәрәм. Бу өлкәдә балалар - бездән, без - балалардан өйрәнәбез. Менә шулай бергә эшләп, яңа технологияләр кулланып, җан-фәрманга рус балаларына татар теле өйрәтәм.

Татарстанда яшәгән рус баласына татар телен генә түгел, аның мәдәниятын, тарихын да өйрәтергә омтылам. Минемчә, бу милләтләр арасында дус яшәүнең серләренә төшендерүнең әһәмиятле бер өлеше дип санайм.

Мәктәбемдә дистә еллар буе тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләү – үзе үк педагогик осталыкка сынау булды. Шушы хезмәтне башкарганда мин бар көчемне мәдәнияткә, сәнгатькә юнәлттем. Укучыларны татар халык биюләренең, сәхнә осталыгының серләренә төшендердем,татар халкының гореф-гадәтләрен саклап калуда үз көчемне керттем.

Татарлар да үз балалары белән рус телендә сөйләшкән бер чорда, рус баласының телебезгә хөрмәт белән карап, тел өйрәнүе – минем педагогик осталыгымның нәтиҗәсе. Явыз Иван чорыннан бирле бер генә татар сүзе дә

яңгырамаган рус авылының балалары, яшьләре мине елмаеп, үз телемдә сәламләп, аралашырга омтыла икән, бу – минем хезмәтемнең җимеше.

Еллар буе туплаган педагогик осталыгымның нәтиҗәсе – минем укучыларымда. Алар бәхетле булсалар, мин дә бәхетле, алар бәхетсез булса, минем дә күңелем китек.

Укытучы булу бер генә дә гади эш түгел... Бу, синең күзләреңә карап торган ничә сабый каршында үзеңнең идеяләрең белән кызыктыра алырдай шәхес була алу. Матурлыкка, рухи үсешкә, үз-үзеңне камилләштерүгә омтылыш уятырдай мисаллар белән балалар күңеленә үтеп керү... Сократ сүзләре белән әйтсәк, укытучы – яңгыр тамчысы сыман. Яңгыр орлыкларны шыттыра алган төсле, укытучы - балада шәхес тәрбияләп, күңелендә матурлык уятучы. Балалар белем һәм тәрбиядән тыш, җылылык, игътибар, ярдәм, таяныч ала икән, арадагы бәйләнеш тагын да тыгыз була.

Укытучы сүзенә тирән мәгънә салынган . Укытучы һөнәр генә түгел, ә күңел халәте дә. Мәктәптән тыш та син укытучы булуыңнан туктамыйсың. Укытучы - психолог та, сердәшче дә, киңәшче дә. Аның киеме, үз-үзен тотышы – барысы да үрнәк булырга тиеш.

Чын укытучы булыр өчен үз фәнеңне тирән белергә, холкыңны, эчке дөньяңны гел камилләштереп торырга, балаларны чын күңелдән яратырга, хөрмәт итәргә, аларны аңларга кирәк. Шулай булганда укытучы һөнәренең авырлыгы сизелмәс, күңелдә эшләнгән эшләргә, ирешкән уңышларга сөенеч, канәгатьлек хисләре генә булыр. Күңелгә шигырь юллары килә.

Әзер юлдан үз көеңә бару җиңел.
Тигез җирдә юл салу да читен түгел
Кыяларга сукмак салу читенрәк!
Тик күңелгә юл салудан җиңелрәк!
Безнең бурыч – күңелләргә сукмак салу!
Сукмак салыр үзәннәрне эзләп табу!
Безнең эш ул – әйтелмәгән сер шикелле.
Безнең эш ул – җырланмаган җыр шикелле.
Торган саен серлелеге артып тора,
Укылмаган китап кебек тартып тора.

К.Булатова

Эш дәверендә барысы да шома гына барды дип әйтү дөрес булмас. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту, шул телгә карата хөрмәт уяту үтә дә катлаулы. Янәшәмдәге хезмәттәшләрем, гаиләм һәрчак миңа таяныч һәм терәк булып тордылар. Бүгенге көндә ирешкән уңышларым, бары тик шул эшемә гашыйк булуымнан дип саныйм.

Татар теле укытучысы буларак минем эшчәнлек чорым бик җавплы заманга туры килде.

-Сезнең эшегез хәзерге вакытта"Чирәм җирен күтәрүгә тиң -,дия иде безгә мәктәт директорыбыз.

Үзем директор вазифасын үтәгәндә дәмин шуны аңладым:балалар белән үзеңне эчкерсезтотарга кирәк.Алар белән шатланырга,алар беләнбергәкөенергә,кирәк булса булышырга ,алар белән бала булып кала белергәкирәк.Иң мөһиме ,җир йөзендәгекешеләрне санга сукмауга юл куймаска.икейөзле мәрхәмәтсез кешеләр азрак булсын иде.

Мин - татар теле һәм әдәбияты укытучысы, милләтебезнең киләчәге, һичшиксез, укытучыларга бәйле дип уйлыйм. Халыкның тереклек иясе һәм милләт буларак бетүдән сакланып калуы өчен милли рух яшәргә тиеш. Рухы тотрыклы кеше генә XXI гасырның наркомания, эчкечелек, фахишәлек, миһербансызлык, кебек коточкыч авыруларына бирешмичә үзен, нәселен һәм милләт вәкиле буларак халкын саклап кала алачак.

Заман зур тизлек белән үсеш, үзгәреш кичерә. Минем иң зур теләгем: мин укыткан укучы үзенең белем дәрәҗәсе, холык – фикер камиллеге белән тормыш сынауларында бирешмәслек булсын.

Мин укыткан, тәрбияләгән бала җөмһүриятебезнең һәм илебезнең күренекле уку йортларында укырлык, нык гаилә корырлык, халкыбызга хезмәт итәрлек булып өлгерсә, мин бәхетле!

Димәк, минем кулымдагы тәрбия корабының руле тормыш диңгезендә дөрес юнәлеш алган.

Мин язмышыма рәхмәтле. Ходай мине шушы хезмәтемнән, таныш сукмагымнан аермасын иде. Һәр көн иртән эшкә ашыгырга язсын.

Һәркемнең үз юлы, үз сукмагы... Шушы нәни сукмаклардан атлаучы укучыларым да киләчәктә киң тормыш юлына аяк басарлар, иншалла!

Мәктәп,мзктәп ,тик син ачтың миңа

Бу дөньяның күркәм серләрен.

Якын шуңа сиңа илткән юллар,

Якын шуңа туган җирләрем.